Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының егерме җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

24 октябрь, 2019 ел № 219

Хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июлендәге 151 номерлы карары белән расланган хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала».

1.2. Нигезләмәнең 3.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Комиссия утырышы муниципаль хезмәткәр катнашында уздырыла, аңа карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала. Комиссия утырышында муниципаль хезмәткәр (яисә граждан) шәхсән катнашу нияте турында әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов